“Замандаш” балалар иҗтимагый оешмасы гәҗите

# УһУ

Укучылар һәм укытучылар гәҗите

N19, март 2020

Бүгенге санда:

* 8 март бәйрәме
* Зәринә белән әңгәмә
* Балтач кызы, Балтач егете
* Безнең кызлар
* Кичә - бүген
* Хатирәләр
* Ажаган! Ажаган!




Беренче тапкыр 1901 елның 8 мартында Америка хуҗабикәләре Чикаго урамнарына кастрюльләр һәм тазлар күтәреп чыга. Чарада катнашучылар сәяси хокукларның тигезләнүен, үзләренә карата хөрмәт, производствода эшләү һәм армиядә хезмәт итү мөмкинлеген таләп иттеләр. 1908 елда АКШта хатын-кызлар көне игълан ителә.

Халыкара хатын-кызлар көне Германия коммунисткасы Клара Цеткин исеме белән дә бәйле. Ул 1910 елда Халыкара хатын-кызлар конференциясендә бөтен дөньяда эшләүче хатын-кызлар бердәмлеге көнен гамәлгә кую тәкъдиме белән чыга.

Россиядә хатын-кызлар көнен беренче тапкыр Петербургта 1913 елның 2 мартында билгеләп үтәләр. Яңа стиль буенча 8 март (искечә 23 февраль) текстиль фабрикасында эшләүче хатын-кызлар забастовкасы була. Тигез хокук таләп итеп хатын - кызлар урамнарга чыгалар. Бу Февраль революциясе башланып китүгә этәргеч була. 1965 елда 8 март безнең илдә ял көн итеп билгеләнә. 1975 елда БМО аны Халыкара хатын-кызлар көне буларак игълан итә.1990 елдан бу бәйрәмнән сәяси төсмер алына. Ул 2002 елда РФ Дәүләт бәйрәмнәре исемлегенә кертелде.

Менә яз да килеп җитте,
Кояш елмаеп көлә.
Беренче бәйрәм булып,
Сигезенче март килә.
Хатын-кызлар бәйрәмен
Хәтта без дә көтәбез.
Без бит сезне яратабыз,
Һәм дә хөрмәт итәбез.
Назлы тавышыгыз белән
Җылытасыз күңелне.
Гүзәл затлар милләтне
Бизәп тора түгелме?!
Безнең тормыш күгебездә
Сез иң якты йолдызлар
Йөрәгегез чиста булсын!
Бәйрәм белән, и кызлар!

Ахкямов Фидаил, 10 сыйныф укучысы

**Зәринә белән әңгәмә**



Гәҗиттә “Зәринә әңгәмәсе” рубрикасын 8 март хатын-кызлар бәйрәменә багышларга кирәк дигән ныклы фикер мине озын тәнәфестә укучылар ратып җыела торган шахмат зонасына китерде. Укучыларның бәйрәм турында уй – фикерләре нинди, аның килеп чыгу тарихын беләләрме, юкмы икәнен ачыклау теләге туды. Гарапшин Камил янында тукталдым.

- Камил, 8 март бәйрәме якынлаша бит! Бу бәйрәмгә ничек карыйсың?
- Яхшы! Әниләр, кызлар бәйрәме бит.
- Бу бәйрәмнең ничек килеп чыкканын беләсеңме?



- Юк.
- Кемне бәйрәм белән котлыйсың килә?

Әнине, барлык туганнарны, кызларны котлыйсым килә. Бәхет телим!

Сыйныфташым Закирова Дилә белән дә әңгәмә кордым. Кызганыч, бәйрәм тарихы белән ул да кызыксынмаган булып чыкты.

- Дилә, бу бәйрәмне син көтеп аласыңмы, әллә ул синең өчен гадәти бер көн кебекме?




- Мин, гомумән, бәйрәмнәрне яратам. Бу бәйрәмне зарыгып көтәм. Туганнарым котлыйлар, бүләкләр бирәләр. Мин дә аларны котлыйм.

Нәбиев Кәримне дә урап үтмәдем һәм көтелмәгән кызык җаваплар алдым:

- Бәйрәм әйбәт инде ул. Бик ошап бетми. Акча күп кирәк.

Кәрим бәйрәм тарихын белә булып чыкты.

- Бәйрәм белән чын күңелдән котлыйм үзеңне, Зәринә! Бүләге почта аша килер, яме.



Укытучыларның да күңел кылларын тибрәтеп алу уе белән технология кабинетына юнәлдем. Рамил Абделбариевичтан әңгәмә корып алырга рөхсәт алганнан соң, аңа да шул ук сорауларны бирдем. Ул бәйрәм килеп чыгу тарихын сөйләп үк бирде. Бәйрәмгә карашы уңай. Әңгәмә ахырында аның хатын - кыз укытучыларга, мәктәптә эшләүче башка барлык хатын-кызларга, укучы кызларга теләкләрен җиткерәсе килде:

Гүзәл затларыбыз! Сезне чын күңелдән яз бәйрәме белән котлыйбыз! Сәламәтлек, иминлек телимен сезгә!

- Рамил абыйга кушылып мин дә бәйрәм беләнкотлыйм, кызлар! Кемнәр 8 март бәйрәме тарихын белми интернет челтәренә кереп укырга киңәш итәм!



## Балтач кызы. Балтач егете.

Районыбызда 3 мартта беренче тапкыр Балтач мәгариф бүлеге инициативасы белән “Балтач кызы”, “Балтач егете“ конкурслары уздырылды. Конкурс шартлары шактый катлаулы иде. Ул Бөек Ватан сугышы, Республикабыз һәм районыбыз тарихына караган биремнәр эшләүне, район йөзен күрсәткән бизнес - проект яклауны үз эченә ала. Милли сәнгатьне белү, сәхнә һәм кул эше остасы булуны да таләп итә. Көндәшләр шактый күп - 35 укучы. Алар эшчәнлегенә мәртәбәле жюри бәя куйды. Катнашкан укучыларыбыз сынатмады. 10 сыйныф укучысы Шәйхетдинов Инсаф — “Баһадир егет” номинациясендә җиңүче, ә 7а сыйныфыннан Хабибуллина Ландыш кызлар арасында беренче урынга лаек булды. Конкурсны барып күрүчеләр аны “традициягә әйләнсен иде”, - дигән теләктә калдылар.








## Безнең кызлар!

2019 елның сентябрь аенда мәктәптә биюче кызлардан «Грация» бию төркеме оешты. Бию төркеме составында 8 -10 сыйныф укучылары. Җитәкчеләре Закирова Гөлчәчәк Рәүф кызы. Төркем инде бүген үзенең чыгышлары белән авыл, район сәхнәләрен балкыта башлады.Ул мәктәп, авыл яшьләре концертларында чыгыш ясый. “Кичке уен” исемле үзгә биюе иң беренче чиратта Балтач мәдәният йортында күрсәтелде. 8 февральдә Норма мәктәбен тәмамлаучылар белән очрашуга да безнең бию төркеме үз өлешен кертте. Әлеге уңайдан Норма мәдәният йортында халык яратып калган “Кичке уен”Һәм “Кызыл шәфәкъ” биюләре куелды Төркем “Созвездие - Йолдызлык ” конкурсында уңышлы чыгыш ясады. 2 февральдә узган “Без бергә“ Республика конкурсының муниципаль этабында татар биюе белән катнашып, кызлар көтеп алган уңышка ирештеләр. Тырышлык һәм алга омтылулары белән конкурсның зона этабына үттеләр. Уңышлар юлдаш булсын сезгә, кызлар!

Гатауллина Әдилә, 10 сыйныф укучысы

## Кичә - бүген



**2018**

***2 ел элек***

10 сыйныф укучысы Гатауллина Адилә “Замандаш” укучы балалар оешмалары активисты, отряд вожатые, укучылар үзидарәсе мәдәният министры иде. Мәктәптә балалар оешмасы эшчәнлеген актив оештыручы булды.



**2020**

***бүген***

Ул 2 ел эчендә үзенең лидерлык сыйфатларын мәктәп, район күләмендәге оештыру эшләрендә, Республиканың профильле лагерьлар сменаларында, төрле конкурсларда, ярышларда катнашып үстерде.Аларның берничәсе:

- “Иң яхшы вожатый 2019” конкурсы “Иң яхшы видео” номинациясендә җиңүче;
WorldSkils Baltasi - 2 урын,
Кэс-баскет – 3 урын;



“Стартинейджер” конкурсында - иң оста биюче ( Королева танцпола ) булып танылды. Республика дәрәҗәсендәге конкурсларда да көч сыный. 2019 елда “Ел лидеры” конкурсында уңышлы чыгыш ясады. Республика Балалар оешмасы союзы проектларында актив катнаша. 2020 елда актив эшчәнлеге өчен бу Берлекнең дипломы белән бүләкләнде. 2020 елда аны “Без бергә” Балтач районы балалар оешмалары лидерлары берлеге советы рәисе итеп сайладылар.

Аның эшчәнлек кредосы: “ Яңаны өйрән, үзең белгәнне башкаларга да өйрәт !”



Адилә һәм аның командасы



“Ел лидеры” конкурсында



22 февральдә 2а, 2в сыйныфларында “Солдатта булган диләр” темага очрашу узды. “Ягез әле, егетләр” уены булды.




27 февральдә «Батыр егет - ил күрке» 1а, 1б, 2б сыйныфлары очен Хасаншин Госман Гомәр улы белән очрашу үтте.

**Сәләхетдин улы Хәйретдин бабам турында хатирәләр.**

Зур гаилә башлыгы, Нурания әбиемнең әтисе Сәләхетдин улы Хәйретдин 1907 нче елда Чапшар авылында дөньяга килгән. Гади бер авыл малае булган. Иген иккән, атлар көткән. Җир малае булганга, бернинди кара эштән дә тартынып тормаган. Туп кебек, түм-түгәрәк, төптән юан чыккан егет булып үсеп җиткән. Аны авыл советы рәисе итеп билгеләгәннәр. Озын толымлы,зәп-зәңгәр күзле матур кызны яр итеп сайлаган һәм гаилә төзегән. Бер-берсен хөрмәт итеп, дөнья мәшәкатьләренә чумып тормыш итә Хәйретдин бабай. Әбием Бибисабира (Нурания әбиемнең әнисе) авыл хатыннарына хас эшләрне башкара. Акрынлап көннәр, айлар үтә. Тупырдап торган 4 бала - Нурания, Сания,Зыятдин, Гөлфия дөньяга киләләр. Һәр туган көнгә сөенеп, тормыш тәгәрмәче тәгәри. Тик мондый бәхетле көннәр озакка сузыла алмый. Бөтен дөньяны тетрәткән Бөек Ватан сугышы башлана. Илгә килгән кара кайгы, бу гаиләне дә читләтеп үтми.
Хәйрулла кызы Бибисабира әби тылда хезмәт куя. Җир сөрә, урак ура,атлар карый,сугышчылар өчен кич утырып оекбаш, бияләйләр бәйли. “Җиңү өчен” - дип, бар тырышлыгын куя. Әле дүрт баланы да тәрбияли.

Бабамнан яу кырыннан берничә тапкыр хатлар килә. Андагы мәшхәрне сөйләп бетерерлек түгел: якындагы башнялар ауган, вагоннар чәчелгән, җир өсте үле гәүдәләр белән тулган, күпме офицер һәм солдат башын салган. Дошман, поездны шартлаткач, үлүчеләр санының чиге булмаган...

Хәйретдин бабам шул китүдән инде кайтмый. Бибисабира әби аның турында бер хәбәр дә алмый. Ул ире турында соңгы көненә кадәр хәбәр көтә. “Үлгәннәр исемлегендә юк, исән ул, бер кайтыр,”- дип көтә .

Гаиләдә олы бала минем Нурания әбием була.Үзеннән соңгы өч ятимне үстереп аякка бастыруда ул әнисенә зур ярдәмче була. Балалар да гомерләре буена әтиләрен көтеп яшиләр.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан-ел ераклаша бара. Ләкин халкыбыз кичергән ул кайгы-хәсрәтләр һичкайчан онытылмас... Бөек Ватан сугышы тәмамланганга, никадәр вакыт үтсә дә, аның хатирәләре күңелләргә тирән сеңеп калган. Язлар җиту белән, Җиңү бәйрәмен билгеләп үткәндә, бу вакыйгалар кабат искә төшә.

Хабибуллин Әмир Ранис улы, 7нче А сыйныфы укучысы

**Мөхәррир киңәшләре.**



22нче февральдә мәктәптә ел саен уза торган "Аҗаган" уены үткәрелде. Чараларда 12 команда катнашты. Абсолют җиңүчеләр - 8а, 10-11 сыйныфлары командалары. 1 урын алучылар - 5а, 6б сыйныфлары.

Креативлык таләп итә торган мөһим чараларның берсе - "Сугышчан бит" чыгару иде. Вакыты чикле - нибары 20 минут. Беренче карашка аз булып тоелган вакыт аралыгында укучылар исем, девиз, мәкалә язарга һәм "Аҗаган" вакыйгаларын чагылдырган рәсем ясарга тиеш иделәр. Ләкин һәр сыйныфның иҗатында үз җитешсезлекләре табылды. "Сугышчан бит " чыгаруда нинди хаталар бар иде? Киләсе елларда аларны булдырмау өчен без нинди киңәшләр бирә алабыз? Алда шуның турында укырга мөмкин.

"Сугышчан бит "тә иң кирәкле элемент, мөгаен, мәкалә булды. Аны язуда берничә хатага ишарә ясарга мөмкин. Беренчедән, күпчелек команда мәкаләгә хәтта исем бирмәгән. Икенчедән, мәкалә ватман битендә тигезле - тигезсез яки бик вак почерк белән язылган. Өченчедән, кайбер команда бу биткә мәкалә кертмәгән, ә кайберләре аның эчтәлеген дөрес бирмәгән.

**Киңәшләр:** вакыйгаларны кызыклы формада, тулы итеп язырга тырышыгыз; почерк аңлаешлы булсын; мәкаләгә кешене җәлеп итә торган исем бирегез.

Күп команданың балын киметкән элемент - рәсем. "Аҗаган"да рәсем ясауның төп шарты - кызыклы хәлләрне яки уеннарны үз кулың белән сурәтләү. Ясалган хаталар: чыгартылган картинкалар куллану, уеннарны сурәттә чагылдырмау, ватман битенең күп өлешен ак килеш калдыру .

**Киңәшләр:** рәсемнәрне үзлектән ясагыз; ачык төсләр кулланыгыз, алар кешедә кызыксыну уята; беренчелекне алам, дип катлаулы сурәт иҗат итү кирәкми - гадиләрен аңлау җиңелрәк; ватман битенә карандашлар ярдәмендә төс кертсәгез яхшы булачак, өстәмә бал алу мөмкинлеге бар.

Исем белән девиз чыгаруда зур кимчелекләр юк. Алай да, бер ассызыклап китәсем килә: исем, девиз һәм мәкаләне татарча язу - ватанпәрвәрлелек билгесе дияяр идем. Димәк, сез миләттегезне зурлыйсыз, яратасыз. "Сугышчан бит" чыгару "Аҗаган"да бал алу өчен генә кирәкми. Моның максаты - туган җиргә карата нәкъ менә горурлык һәм ярату хисләрен уяту.

Хөрмәтле укучым! Киләсе елда булачак “Аҗаган” уенында бу киңәшләрне исеңдә тотарсың дип ышанып калам.

Зарипова Динә, “УҺУ” гәҗите мөхәррире

## Туган ягым Кили



Туган ягым минем Кили,
Урман аның күршесе.
Башка яктан тау да чикли,
Челтерәп ага инеше.
Тау битләрендә җәен
Кызарып пешә җиләк.
Болыннарыннан чәчәк җыям
Әнием өчен бүләк.
Килием, күпме кайгы,
Хәсрәт кичергәнсең син...
Тик ниләр кичерсән дә,
Яшә авылым, яшә син!

Кабиров Булат, 7а сыйныфы укучысы

## Белдерүләр

**Игътибар !**

Алдагы атнада Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышлап барлык сыйныфларда да эзләнү, практик иҗади сәнгать эшчәнлеген үз эченә алган күмәк эшләр проектларын тормышка ашырылу көтелә. Барлык сыйныфларда да әзерлек эшләре бара.

**Игътибар!**

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гәҗиттә даими рубрикалар булдырырга телибез. Сездән хезмәттәшлек итү көтәбез. Нинди язмалар күрергә телисез? Нинди бүлекләр куяр идегез? Бәлки гәҗит чыгаруда катнашырга телисездер? Сездән тәкъдимнәр, проектлар көтәбез. Киләсе санда “Нәниләр бите” рубрикасы дөнья күрәчәк.

**Редколлегия:** Зарипова Динә, Җәләева Зәринә, Гаязова Нәзилә